КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

БОЕРЫК
09.07.2024 №149-п

БОЕРЫК

«Татмедиа» матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
буенча республика агентлыгының
дәүләт граждан хезмәткәрләренең
хезмәт тәртибе таләпләрен
үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын
җайга салу комиссиясе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне;

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының 2016 елның 1 июлендәге 21-п номерлы боерыгын;

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Комиссиясе турында Положениегә үзгәреш кертү хакында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2018 елның 05 апрелендәге 8-п номерлы боерыгын;

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында» «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының 2023 елның 29 мартындагы 58-п номерлы боерыгының 2 пунктын.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны җитәкченең беренче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче

Казан шәһәре
«Татмедиа» матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр буенча
республика агентлыгының
_______________боерыгы белән
расланды

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба - Нигезләмә, Комиссия, Агентлык) турындагы нигезләмә «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә эшләнде һәм Комиссияне оештыру һәм аның эшчәнлеген җайга салу тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүне, шулай ук алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итү (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләр);https://internet.garant.ru/ -/document/12164203/entry/0

Агентлыкта коррупцияне кисәтү чараларын тормышка ашыру.

1.4. Комиссия Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфаларын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) карата хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карый.

Агентлыкта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

1.5. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия җитәкче (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – җитәкче) тарафыннан Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләнеп куела торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) җитәкченең беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Агентлык кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), Агентлыкның җитәкче билгели торган бүлек хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Җитәкче “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләрен, Агентлыкның башлангыч һөнәри берлек оешмасын һәм ветераннарның иҗтимагый оешмасын комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына, тиешле органнар һәм оешмалар белән килештереп, җитәкче тәкъдиме белән кертелә. Килешү тәкъдимне алган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләми торган Комиссия әгъзаларының саны Комиссия әгъзаларының гомуми санынnan кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул иткән карарга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычын булдырмауны истә тотып төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы хокукына ия түбәндәгеләр катнаша:

а) Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу хакындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Агентлыкта Комиссия тарафыннан бу мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре биләгән шундый ук дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче, Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән ике дәүләт хезмәткәре;

б) Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле - Комиссия рәисе карары буенча, ул Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн кала бу мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы үтенече буенча һәр очракта аерым кабул ителә.

2.8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынnan кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү мөмкин түгел.

2.9. Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда Комиссия әгъзасының мәнфәгатьләр каршылыгына китерерлек турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы бу турыда хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) җитәкченең дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, аның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәвен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне раслый торган материаллар тапшыруы:

дәүләт хезмәткәренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан

керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәдә каралган белешмәләрне дөрес итеп һәм тулысынча тапшырмавы;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве;

б) кадрлар бүлегенә Агентлыкның норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр керү:

Агентлыкта дәүләт хезмәтен биләгән вакытта керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында  белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Агентлык боерыгы белән расланган исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел узганчы коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә  коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе нигезендә эшләр башкаруга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате, әгәр әлеге оешма белән идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

Дәүләт хезмәткәренең счетлары (кертемнәре), акчасы һәм кыйммәтле әйберләре сакланган һәм (яисә)  финанс инструментлары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге дәүләт законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яисә үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар аркасында  “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итүе;

в) комиссия җитәкчесенең яисә аның теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибе таләпләренең үтәлүен һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуны тәэмин итүгә яисә коррупцияне кисәтү буенча Агентлыкта гамәлгә ашыруга кагылышлы күрсәтмәсе;

г) җитәкченең дәүләт хезмәткәренең «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыруын таныклый торган тикшерү материаллары тапшыруы;

д) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 641 статьясы нигезендә Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эш башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсе төзү турында хәбәрнамә керү, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның Агентлыкта вазыйфаны биләгән вакытта үтәгән вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса (күрсәтелгән гражданинга Комиссия тарафыннан элегрәк әлеге оешма белән хезмәт яисә граждан-хокукый мөнәсәбәтләренә керүдән баш тарту яисә мондый гражданга аның коммерциячел оешмада яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенә яки аның граждан-хокукый шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруына ризалык бирү турында мәсьәлә Комиссиядә каралмаган булу шарты белән)

е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә каршы килә торган үзенә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында хәбәр итүе.

3.2. Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешманың исеме, урнашу урыны, аның эшчәнлек характеры, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән вакытта граждан тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) вазыйфалары, коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешмага карата дәүләт идарәсе функциясе, килешү (хезмәт яисә граждан-хокукый) төре, аның гамәлдә булу срогы, шартнамә буенча эш (хезмәтләр) үтәгән өчен түләү суммасы күрсәтелә. Кадрлар бүлегендә мөрәҗәгать карала һәм аның асылы буенча, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мотивацияләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән китәргә җыенучы дәүләт хезмәткәре тапшырырга мөмкин һәм ул Комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәү турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерли.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр әзерләгәндә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләгән өчен җаваплы зат мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә биргән граждан хезмәткәре белән әңгәмәләр үткәрергә һәм аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Агентлык мәгълүмат алу өчен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга, шул исәптән «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, запрослар җибәрергә мөмкин. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук йомгак һәм башка материаллар килгән көннән алып җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Сораулар юлланган очракта мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д», "е" пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карар кабул итү өчен киңәшләр.https://internet.garant.ru/ -/document/407776310/entry/1315

3.5. Комиссия рәисе Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Бу чакта Комиссия утырышы датасы әлеге мәгълүмат кергән көннән алып 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә, моңа әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклар керми;

б) Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар бүлегенә кергән мәгълүмат белән, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту) турында карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт граждан хезмәткәре яисә агентлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга нияте турында дәүләт граждан хезмәткәре яисә гражданин әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчалары нигезендә бирелгән мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары дәүләт граждан хезмәткәре яисә граждан үзе булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчаларында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт граждан хезмәткәренең яисә гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге барлыгы күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга теләүче һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт граждан хезмәткәре яисә гражданин Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган сорауларның асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында үзләренә мәгълүм булган мәгълүматларны фаш итәргә тиеш түгел.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы

дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәдә каралган белешмәләрнең дөрес  һәм тулы булуын билгеләргә;

б) әлеге пунктның икенче абзацында аталган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөрес түгеллеген һәм (яисә) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәнен билгеләргә. Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәүнең ярамаганлыгы турында күрсәтергә һәм яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада граждан-хокукый шартнамәсе шартларында эш башкаруга ризалык бирү, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

б) гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада граждан-хокукый шартнамәсе шартларында эш башкаруга ризалык бирүдән баш тарту, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керә торган булса, һәм бу баш тартуны дәлилләү.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау сәбәбе объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмау сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләр объектив һәм нигезле дип танырга;

б) “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләр объектив һәм нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын танырга;

б) дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт граждан хезмәткәренә һәм (яисә) җитәкчегә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яисә аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт граждан хезмәткәре мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт гражданлык хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012

елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырган белешмәләрнең дәрес һәм тулы булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә  туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырган белешмәләрнең дәрес һәм тулы булмавын танырга Бу очракта Комиссия җитәкчегә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга һәм (яисә) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны компетенцияләре нигезендә прокуратура органнарына һәм (яисә) башка дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданның коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) гражданның коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләве һәм (яисә) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада эш башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия җитәкчегә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм аңа хәбәр иткән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү  һәм хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү арасында  бәйләнеш булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү  һәм хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү арасында  бәйләнеш булмавын танырга;

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала.  Мондый карарны кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылыш табарга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Агентлыкның норматив хокукый актлары проектлары,  карарлар яисә йөкләмәләр проектлары әзерләнә, алар билгеләнгән тәртиптә җитәкче каравына тапшырылырга тиеш.

3.21. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән  кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга Комиссия утырышында катнашкан әгъзалар имза сала. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карардан тыш, җитәкче өчен тәкъдим рәвешендә була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри үтәлергә тиеш.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта);

б) Комиссия утырышында карала торган һәр сорауның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү турында һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәү хакындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы күрсәтелгән формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата дәгъва белдерелә торган, алар нигезләнә торган материаллар;

г) белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәре һәм башка затлар аңлатмасының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта);

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, аның Агентлыкка керү датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) аны кабул итү карары һәм нигезләмәсе.

3.24. Комиссия әгъзасы, аның карары белән килешмичә, үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән алып җиде көн эчендә җитәкчегә, тулысынча яисә аннан өземтә рәвешендә дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

3.26. Җитәкче Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм дәүләт хезмәткәренә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә үз компетенциясе чикләрендә, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен һәм кабул ителгән карарны карау турында җитәкче язма рәвештә Комиссиягә утырыш беркетмәсе кергән көннән алып бер ай эчендә хәбәр итә. Җитәкченең карары комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.

3.27. Комиссиясе тарафыннан дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар хокук бозу билгеләре билгеләнгән очракта, бу хакта мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый

актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җитәкчегә тапшырыла.

3.28. Комиссия дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яисә җинаять составын үз эченә ала торган гамәл кылуы фактын (гамәл кылмау фактын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлнең кылынуы (гамәл кылынмавы) турында мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3 көн эчендә, ә ихтыяҗ булганда – кичекмәстән, хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан өземтә хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә кушып куела.

3.30. Комиссия секретареның имзасы һәм җитәкче мөһере белән таныкланган өземтә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданга  имза куеп тапшырыла яисә комиссиянең тиешле утырышы уздырылган көннән алып бер эш көне эчендә белдерүле заказлы хат итеп ул мөрәҗәгатьтә күрсәткән адрес буенча  җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру, кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы  вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Татмедиа»  матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр  буенча
республика агентлыгының
_______________ боерыгы белән расланды

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе**<br><br>Әхмәтова<br>Эльвира Фәнис кызы | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| **Рәис урынбасары**<br><br>Миргалимов<br>Илдар Флүс улы | «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Латыйпова<br>Гүзәл Рәшит кызы | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының кадрлар бүлеге башлыгы |
| Корсуков<br>Михаил Николаевич | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының юридик секторы мөдире |
| Гарифуллин<br>Васил Заһит улы | Казан (Идел буе) федераль университетының Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институты Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең милли һәм глобаль мидиа кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Рәхимов<br>Салават Фоат улы | Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге баш киңәшчесе (килешү буенча) |

**Комиссия секретаре**

Сметанина
Анна Александровна

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы баш белгече